Фәния Шакирова



# ОЧАР КОШЫМ

## Туган як шагыйрәсе

Шигърият күгендә калыккан һәр яңа исем иясе гадәттә яшь һәм йөрәк- күңел хисләре кайнап торган егет я кыз була. Без инде шуңа күнеккәнбез, башка төрле фикерне кабул итү гаҗәеп читен сыман.
Ә Фәния апа Шакирова, менә, инде яшь кыз түгел, өченче ел буе лаеклы ялда яши. Әмма аның турында "ул карт кеше" дип әйтергә тел әйләнми. Чөнки Фәния апаның йөрәге яшь. Аның күңелендә кайнаган мул хисләр, күкрәгендәге шигърият чишмәсе меңәрләгән яшь кызларныкына биргесез.
Аның йөрәгендәге шул хисләр ак кәгазъ битләренә сәйлән булып яткан. Шуңа күрә аның исеме шигърият мәйданына чыгаруга лаек.
Аның гомер юлы гади дә , катлаулы да. Ул 1939 елда элеккеге Бондюг районының Бәзәкә авылында дөньяга килгән. Шуннан бирле туган авылыннан киткә чыгып йөрмәгән, бәхетләрен дә, хәсрәтләрен дә шунда кичергән. Ә язмыш дигәннәре бик үк назламаган шул аны. Аның әтисе меңәрләгән татар ирләре кебек үк Бөек ватан сугышында һәлак булган. Фәния сабый чагыннан ук ятимлек, мохтаҗлык михнәтләрен кичереп үскән. Ләкин усал язмыш аны алга таба да аямаган. 1965 елда әнисе вафат булганнан соң Фәния үзенең кечкенә энесенә әни урынына калган. 1986 елда ире Әхмәтгәрәй вафатыннан соң Фәния ханым өч ятим баласын да берүзе аякка бастырган. Үзе гомер буе колхоз эшендә, күбесенчә терлекчелек өлкәсендә, фермада тир түккән.
Бу кадәрле авырлык һәм хәсрәт, мөгаен, башка кешене сындырыр иде. Ә Фәния апаның, менә, һәрвакыт күңеле көр, йөзе ачык, мохтаҗ булганнарга ярдәм кулы сузарга ул һәркөнне әзер. Моның сере бик катлаулы түгел. Ул җаны-тәне белән туган җиренә, туган халкына гашыйк кеше. Аның күңеле тулы шигърият һәм моң. Әнә шул шигъри күңеле аңа яшәргә көч бирә.
Йөрәгендәге хисләре шигырьләренә күчә бара. Шуңа күрә авылдашлары да , районнашлары да "безнең шагыйрә" , дип олылап йөртә. Аның җырларын телдән-телгә күчереп кабатлыйлар. Аны яраталар. Бу китапның дөньяга килүе дә - шул хөрмәт-мәхәббәткә олы бер шаһит.
Китапка һәм аның иясенә Ходай тәгалә озын гомер бирсен.

Вахит Имамов. 1февраль, 1997 ел.

## Бәхетле булыр идем

Мин бәхетле булыр идем
Дусларымның күңелен тапсам,
Кайгыларын-сагышларын
Уртак итеп бүлә алсам.
Мин бәхетле булыр идем
Егылганнарны торгызсам,
Юксылларның әрнүләрен
Басар өчен дәва тапсам.

Мин бәхетле булыр идем
Халкым өчен хезмәт итсәм.
Шигырым белән илемә
Һәм җиремә ярдәм итсәм.
Мин бәхетле булыр идем...

**Туган авылым**

Әнкәм чит җирләрдә түгел,
Үз авылымда мине тудырган.
Челтер чишмәләрнең суын эчеп,
Инешендә битем юдырган.
Язмыш мине тудырды да,
Туган җиремдә калдырды.
Салкын кышы чыныктырды,
Җәйге кызуы яндырды.
Ташларына бастым яланаяк,
Тауларына мендем, үрмәләдем.
Бәхетләр дә күрдем, кайгылар да –
Халкымнан җәбер күрмәдем.

**Алтын, көмеш**

Киерелеп печән чабам,
Туган җир суларын эчәм,
Үз илем һавасын исним,
Үз җиремдә тормыш кичәм.
Туган җирдә бик кадерле
Эшләп йөргән бар эшем дә.
Чит җирләрнең кирәк түгел
Алтыны да, көмеше дә.
Үз илемдә, туган җирдә,
Авылымда миңа өлеш.
Туган җирнең бар туфрагы
Миңа алтын, миңа көмеш.

**Дәва**

Язмыш миңа никтер елмаймады,
Әллә ничек үксеп карады.
Чәчләремә ак бәсләрен сибеп,
Сагыш тараклары кадады.
Күрсәтмәдем, гел яшерә белдем
Яшьләремнең ачы тамчысын.
Баш имичә горур атлый бирдем
Татысам да язмыш камчысын.

Тормыш бусагасын уза-уза
Талчыкса да аяк-кулларым,
Шигырьләрем миңа юлдаш булды,
Таянычым булды җырларым.

**Туган телем**
Үз телемне хөрмәт итәм –
Газиз телем, ана телем.
Туган телем белән әйттем
Иң беренче “әнкәй” сүзен.
Үз телемдә сөям-көям,
Үз телемдә укыйм-язам...
Анаң телен оныта күрмә,
Оныта калсаң, авыр, балам.
Туган телнең изгелеген
Сабыйлар да аңласыннар.
Телне-вөҗданны югалтып,
Маңкорт булып калмасыннар.

**Сагынып көттек**
Татар, дип изделәр,
Татар, дип көлделәр.
Гөнаһсыз татарны
Себергә сөрделәр.
Изелде динебез,
Киселде манара.
Кан-яшьләр түгелде,
Кем түзсен соң аңа?..
Татарым, болгарым –
Бер булып барсы да
Ирекkә үрелде,
Соңы уң булса да.
Түзүләр күп булды
Эшләүләр, тырышып.
Ә хәзер хөр илгә
Бир, Ходам, уңышлык.

**Кызлар тавы**
*Явыз Иван афәтеннән авылыбызны, динебезне саклап калган каһарман бабаларыбызның якты истәлегенә багышлыйм*
Кызлар тавы, Кызлар тавы...
Аларга күп серләр сыйган,
Алар күпнең рухи җанын,
Татар нәселен саклап калган.

Һәр ел саен җәйләр җиткәч
Кызлар чокырына барам,
Тауларыннан җиләк җыям.
Үзәненнән печән чабам.
Утырам да уйга калам:
Искитмәле матур таулар,
Авыл халкын нык саклаган,
Үталмаган аңа яулар.
Җилләр, җилләр, шаян җилләр,
Сөйләгез, таулар турында.
Бу тауларга сез бит шаһит,
Ни булган соң бу урында?
Элек урман каплап торган,
Хәзер инде шәрә таулар.
Хәтерләрендә ни саклый,
Нинди булган монда таңнар?
Дулкын-дулкын тезелгәннәр,
Текәләр таулар, горурлар.
Игезәк кызлар шикелле
Берсенә-берсе якыннар.
Кызлар тавы, Кызлар тавы...
Сафлык өстисең җаннарга.
Кызлар шавы, яшьлек нуры
Сеңеп калган бу тауларга.
Сокландыргыч, гүзәл таулар,
Бер биек тау бигрәк үзгә.
Әйтерсең лә, калфак кигән
Сылу кыздай күренә күзгә.
Хәтфә кебек яшел үлән,
Көтүчеләр көтү көтә.
Горур булып утырган тау
“Калфаклы тау” исемен йөртә.
Тау битендә уйдак-уйдак
Үсә яшел абагалар.
Җан көйдергеч күп хәлләргә
Абагалар шаһит алар.
Могҗизалы бу тауларга
Карап торам исем китеп.
Калган аз-маз агачларда
Кошлар сайрый чут-чут итеп.
Җилләр генә исеп йөри,
Ә кызлар соң кая киткән?
Кызларныңмы сагышыннан
Кара урман корып беткән?
Балта, чалгы, сәнәк алып

Ислам динен саклаганнар.
Дошман явын үткәрмичә,
Керер юлын каплаганнар.
Кыз-хатыннар урманнарда
Яшәгәннәр өркеп-куркып.
Алар анда качып яткан
Җеп җегерләп, киндер тукып.
Бәзәкәгә керер өчен
Өч чакырым гына калган.
Авыл халкы кан-яшь түккән,
Кайгы-сагышларга тарган.
Бер кечкенә инеш ага,
Ярларында үсә таллар.
Бәзәкәлеләр кертмәгәч
Исән калган күп авыллар.
Ил картлары көрәшмәсә
Атмас иде алсу таңнар.
Явыз Иван золымыннан
Көяр иде изге җаннар.
Явыз Иван җәбереннән
Телебез, динебез көяр иде.
Вәхши Иван авылларга
Чиркәүләрен өяр иде.
Авыл халкы сак тормаса
Безне Иван изәр иде.
Мөселманнар күкрәгенә
Тәреләрен тезәр иде.
Мең дә биш йөз илле өчтә
Явыз Иван басып кергән.
Җәберләргә түзә алмыйча
Меңләгән җан шәһит киткән.
Дошманнарга баш бирмичә
Төпләгәннәр алда килер көнебезне.
Гомерлеккә ядкарь итеп калдырганнар
Безгә ислам динебезне.
Шөкер итеп гомер итәм,
Күз тимәсен динебезгә.
Кайгы-хәсрәт иңмәсен лә
Безнең алгы көнебездә.
Бу тарихи могҗизаның
Чын барлыгын белеп калыйк.
Мөэмин җанлы бабайларга
Иман укып, дога кылыйк.

**Күңелкәем яшь минем**
Гомер узды, картаелды, диләр,
Ә мин әле һаман ашыкмыйм.
Олыгайсам да күңелем яшь сыман,
Шигърияткә, җырга гашыйкмын.
Еллар узды, күпме сулар акты,
Бүген уйлыйм әле үткәнне.
Сизмичә дә, күрмичә дә калдым
Картлыгыма килеп җиткәнне.
Бу күңелкәй ник картаймый икән
Үткән юлы авыр булса да?
Күңелләрнең яшен белеп булмый
Чәчләреңә бәсләр кунса да.

**Сәкинәкәй**
Инешкә кушылып ага
Яз җиткәч кар сулары.
Язгы ташкыннар шикелле
Йөрәкнең ярсулары.
Басма өсләренә басып
Чайкыйсың керләреңне.
Синнән бүтәнгә сөйләмәм
Булган эч серләремне.
Сәкинәкәй, керләреңне
Эләсең тезеп-тезеп.
Елмаеп карап аласың
Үзәккәемне өзеп.
Ник бу кадәр сөйкемледер
Синең кара күзләрең?
Сәкинәкәй, көтәм синнән
Сөям, дигән сүзләрең.

**Ак чишмә**
Ак чишмәнең суларыннан
Мөлдерәмә чиләгем.
Ак чишмәдән аерылсам,
Ничек итеп түзәрмен.
Әй, ак чишмә, ак чишмә,
Борылмалы юлларың.
Янган йөрәгеңне баса
Шул шифалы суларың.
Ак чишмәнең суларында
Юам беләкләремне.
Сиңа карап әйтәм изге ,

Сихри теләкләремне.
Бөрешлегә еш кайтамын,
Ак чишмә суы тарта.
Ак чишмә суларын эчсәм,
Мәхәббәт хисем арта.

**Чияләр**
Өй артында матур булып
Үсә безнең чияләр.
Күңелемдәге сагышларны
Алар каян сизәләр?
Әй, чияләр, чияләр,
Хәлең ничек, дияләр.
Өй артында чияләрем
Чәчәк ата ел саен.
Тәрәзәмнән карый-карый
Хәл беләләр көн саен.
Әй, чияләр, чияләр,
Хәлең ничек, дияләр.
Иртән торсам тәрәзәдән
Чияләргә эндәшәм.
Ак чәчәккә төренгәннәр,
Серләшәм дә, көнләшәм.
Әй, чияләр, чияләр,
Хәлең ничек, дияләр.

**Яшьлегем кире кайтса**
Ромашкалар җыям кочак-кочак,
Такыялар үрәм башыма.
Хыялымда яшьлегемә кайтам көн дә,
Син дә чыгарсың күк каршыма.
Чәчәкләрне өзелеп яратамын,
Гомерем буе сөеп назлыймын.
Яшьлеккәйнең газиз-кадерлеген
Олыгайган саен аңлыймын.
Хуш исләрен бөркеп ромашкалар
Һәр җәй саен чәчәк атсалар,
Мин,әй,сөя белер идем Җирне
Яшьлекләрем кире кайтсалар.

## Әнкәемнең сүзләре
Килче минем яннарыма,
Утыр әле син, балам.
Тормыш юллары катлаулы
Синең өчен мин янам.
Кешеләргә кайгы килсә,
Әйтә күрче татлы сүз.
Әгәр сиңа хәвеф килсә
Тешләреңне кысып түз.
Масайма син бәхет иңсә,
Сөйлә уйлап сүзеңне.
Сөенечеңне уртаклаш
Һәм каралтма йөзеңне.
Аккан судай гомер уза,
Истә әнкәм йөзләре.
Хәтеремнән һич җуелмый
Әнкәемнең сүзләре.

## Очар кошым
***Марсель Гыймазетдинов истәлегенә багышлыйм.***
Очар кошым очты-китте, тоталмадым.
Очар кошка китмә, диеп әйтә алмадым.
Очар кошым ерак китте, кайта алмас.
Бүтән кошчык очар кошка тиң булалмас.
Очар кошны уңнан көтмим, сулдан көтмим.
Бәхет миңа кире кайтмас, өмет итмим.
Очар кошым, нигә инде очып киттең,
Нигә соң син безне шулай ятим иттең?..

## Изге чишмә
Баллы чишмә,челтер чишмә,
Җырлый чишмә талгын көйгә.
Син бу талга яшәү бирдең,
Горурлана мәгърур көчкә.
Өч кешенең буе битмәс
Кочакларга талның билен.
Син үзеңнең шифаң белән
Талга бирдең озын гомер.
Талларыңда кошлар сайрый
Китәсе дә килми һич тә.
Чишмә изге булганга да
Ия бит ул шундый көчкә.

**Мәңгегә килмәдең**
Дошманнар урынсыз
Йөрәкне телгәләр.
Дусларың күп булса
Кайгыңны бүлгәләр.
Авырлык килгәндә
Суз ярдәм кулыңны.
Матурла, әй , кеше,
Барачак юлыңны.
Бирәүгә килә ул
Кайгылар итәрәк.
Кемгәдер килә ул
Картаеп китәрәк.
Ярдәмчел бул, кеше,
Начарлык уйлама.
Мәңгегә килмәдең
Бу фани дөньяга.

**Яшәү дәрте**
Җиргә колак куеп тыңлыйм:
Машиналар тыз-быз уза,
Комбайннар иген ура,
Буровойлар чаңын суга.
Тракторкайлар гөр-гөр килеп.
Ташлар җәеп, юллар сала.
Наратлыкта кошлар сайрый-
Җанга шатлык иңеп кала.
Канатларын кага-кага
Биек күктә очына тургай.
Амбарларга ашлык кайта,
Уңыш мулдан булган бугай.
Яшәү көчен, яшәү дәртен
Рухи җаным белән тоям.
Илләр тыныч булсын, диеп,
Һәр иртәдә дога кылам...

**Әйтелмәгән сүз**
Көннәр ага, еллар ага,
Һәркөн алсу таңнар ата.
Күңелемнең иң түрендә
Әйталмаган сүзем ята.
Алсу таңнар гел-гел атсын,
Бәхет бирсен көнебезгә.

Якты кояш нурын илтсен,
Шатлык иңсен йөзебезгә.
Бәхет, гыйшык нурларыннан
Гел елмаеп торсын йөзең.
Кабул итеп алырсыңмы
Әгәр әйтсәм “сөям” сүзен?

**Беренче кар**
Беренче кар ява, беренче кар,
Нур бөркелә шушы аклыктан.
Сабый бала кебек сөенәмен
Акка чумган җиһан сафлыктан.
Агачлар да ак күлмәкләр кигән
Туйда күргән кыздан көнләшеп .
Беренче кар бәхет алып  килсен.
Җир сөенсен таңга эндәшеп.

**Мәхәббәт сүрелми**
Юлыбыз аерылды, киселде өметләр,
Син киттең еракка-еракка.
Өзелде үзәгем; киселгән өметтән
Чыдармы йөрәгем озакка?
Сызылып тан атса да, йолдызлар батса да,
Йөрәктән сагышлар һич китмәс.
Уйланма, күңелем, моңланма, күңелем,
Ул кайтмас, барыбер , ул кайтмас.
Ник киттең, кадерлем, калдырып ялгызым?
Яшәргә иде бит гел бергә.
Гомерләр узалар, киемнәр тузалар,
Мәхәббәт сүрелми мәңгегә.

**Илтче, җилкәй**
Сагышларымны сөйлимен
Әкрен искән җилләргә.
Җилләр аша хәбәр бирәм
Өзелеп-өзелеп сөйгәнгә.
Тапсаң, җилкәй, сөйгәнемне
Әйтермен рәхмәтемне.
Илтче, җилкәй, сөйгәнемә
Сагыш, мәхәббәтемне.
Өзелеп-өзелеп сөйгәнемнән
Җавапка өмет итәм.
Көт, кайтырмын, дисә әгәр
Күпме булса да көтәм.

**Вәгъдә бирмә**
Буш вәгъдәләр бүләк итеп
Табалмассың кирәкне,
Алдан вәгъдә биреп куеп
Әрнетмәче йөрәкне.
Күпләр бу җиһанда төпсез
Вәгъдәләр белән коя.
Үтәлмәгән ул вәгъдәләр
Йөрәк-бәгырьне уя.
Буш вәгъдәләр бирүчеләрнең
Һич алга китмәс эше.
Вәгъдә бирсәң үтәү кирәк –
Шунда кешенең көче.

**Кара миләш**
Өй янындагы бакчага
Иркәм утыртты миләш.
Кайгыларга бирешмә , дип
Бирә ул миңа киңәш.
   Кара миләш, кара миләш,
   Бирә ул миңа киңәш.
Һәр ел саен  кара миләш
Ак чәчәккә күмелә.
Кара миләшләргә карап
Үзәккәем өзелә.
   Кара миләш, кара миләш,
   Бирә ул миңа киңәш.
Өй янында кара миләш
Ядкарь, истәлек төсе.
Кайгым бик ачы булса да
Кара миләшем төче.
   Кара миләш, кара миләш,
   Бирә ул миңа киңәш.

**Арта сөю хисләрем**
Нинди ямьле, җанга рәхәт
Шау чәчәкле аланнар.
Урман-болыннардан җыям
Җиләк-җимеш, баланнар.
Әллә инде бәйрәм бүген –
Кошлар моңлы сайраша.
Бал кортлары гөж – гөж килә,
Нинди рәхәт тамаша.
Яшел печәнлектә ауныйм,

Тоям үлән исләрен,
Йөрәгемә көч өстәлә,
Арта сөю хисләрем.

**Ике чишмә**

(шаян көйгә)
Бәзәкдә ике чишмә -
Баллы чишмә, Зур чишмә.
Көн дә кил, иркәм, чишмәгә,
Колонка суын эчмә.
Кичен суга килерсең, дип
Мин өзелеп көтәмен.
Битләреңнән үбәрмен, дип
Әле өмет итәмен.
Сихәтледер чишмә суы,
Кил, су эчәрбез, иркәм.
Үпкәләүләрең гел бетәр
Иренеңнән үк үпсәм.
Алма-апельсиннар кайткан
Авылым кибетенә.
Бир кулыңны, ярга чыгыйм
Бәзәкә егетенә.

**Яшьлекләр үтә һаман**

Сизелми дә, күренми дә,
Елларны узып барам.
Яшьлекләрем кире кайтмас –
Картлыкка күпер салам.
Гомрем йомгагы – күпернең
Изгелеген күрсәмче,
Исән-имин, сау-сәламәт
Картлыгымда йөрсәмче.
Елларыбыз буталчыклы,
Никтер үзгәрде заман.
Авыр-җиңел, диеп тормый,
Яшьлекләр үтә һаман.

**Нечкәрә күңелләр**

Очар кошчыклар шикелле
Гомернең агышлары.
Татарны кая чәчмәгән
Ходайның язмышлары?

Чаптар атлардай чабышып
Гомерләр ник узалар?
Чәч агартып , маңгайларга
Еллар сызык сызалар.
Җилләр кебек  җитез генә
Уза икән гомерләр.
Олыгайган саен никтер
Нечкәрә бит күңелләр.

## Сизелми уза гомер

Сизелми дә уза гомер,
Алтын көз дә килеп җитте.
Кырда үскән ипекәйләр
Амбарларга кереп бетте.
Шөкер итеп яши бирик,
Быел уңыш шактый мулдан.
Чын намус белән эшләсәң
Һәр эш килә безнең кулдан.
Илләр имин, тыныч булсын,
Кабул булсын безнең уйлар.
Шушы көзге байлыкларда
Гөрләп торсын матур туйлар.
Икмәге һәм яшелчәсе,
Җиләк-җимеш – бар да байлык.
И, ходаем, кайгы бирмә?!
Шат яшәсен һәрбер халык.

## Шаян такмаклар

Алма чәчәкләре аклы
Аклы күлмәкләр төсле.
Әйтеп аңлатырлык түгел –
Мәхәббәтләрем көчле.
    Аклы күлмәкләрем аклы,
    Итәкләре – бәбәй итәк.
    Гыйшыгымны сөйләр идем
    Сөйгәнкәемә әйбәтләп.
Керләремне чайкыйм әле
Басмага кереп кенә.
Байтак гыйбрәтләрне җыйдым
Читләрдә йөреп кенә.
    Чайкаган керләрне киптер
    Бауларга селкеп элеп.
    Нинди сүзләр әйтәсең бар,
    Никләр йөрисең көлеп?

Җилкәй, җилкәй, йомшак җилкәй,
Алып кил изге хәбәр.
Изге хәбәрләрсез торса
Кайгы үзәкне өзәр.
    Өстемдәге күлмәгемнең
    Тукымасы – бумазый.
    Үтә микән берәр төнем
    Син дустымны уйламый?
Яшь чагында киемнәрнең
Матурын киям әле.
Күңелемә кемнәр ошый
Шуларны сөям әле.
    Өстеңдәге итәгеңнең
    Кырыйлары ерыкмы,
    Минем ярым берәү генә,
    Синең ярың кырыкмы?
Кайларда йөрисең , диеп
Бүтән миннән сорама.
Яр өстенә яр сөяргә
Каян алдың син права?
    Җәйләр биткәч тау битеннән
    Җыям каен җиләге.
    Иске яр, диеп ташлама,
    Булыр берәр кирәге.
Җиләк-җимешләргә барсам
Чиләгем бик тиз тула.
Сөйгәнеңне ятка бирмә,
Алуы кыен була.
    Тәмле итеп солы ашый
    Атлар тимер улакта.
    Син нәрсә уйлыйсың микән,
    Мин карамыйм уйлап та.
Өстеңдәге күлмәгеңнең
Бизәге шакмак-шакмак.
Сиңа бүтән булмас, димә.
Бетмәс синдәй бер ахмак.
    Яшь чагымда кигән идем
    Чабаталарны сөеп.
    Сиңа тагынниләр булды.
    Башың йөрисең иеп.
Яшь чагымда аягыма
Чабаталар кимәдем.
Синнән башка беркемне дә
Өзелеп-өзелеп сөймәдем.
    Хәзер инде туфлиләрнең

Лакаваен киямен.
Синнән башканы да таптым,
Өзелеп-өзелеп сөямен.
Яр сөюне авыр, диләр,
Һич авыр түгел икән.
Тик ул гына , чәчәк сайлап,
Кайларда йөри икән?
Алтын тапсаң алга ман,
Бакыр тапсаң балга ман.
Бигрәк кадерле икән бит
Өзелеп сөйгән, газиз җан.
Бәлешләрнең капкачларын
Майлап ашамак кирәк.
Яшьли сөйгән яркайларны
Ничек ташламак кирәк?
Ясалма бизәнү белән
Матур булып күренмә.
Сиңа берәү җитеп торыр,
Башкаларга үрелмә.